| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2017 Казан ш. № 5-79/тэ

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2015 № 5-48/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2018 елга «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан, 2018 елга җайга салынулы оешманың планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РСК» ҖЧҖ тарафыннан җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2016-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2015 № 5-48/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.01.2016 № 5-1/тэ, 16.12.2016 № 5-63/тэ карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, шушы карар кушымтасына туры китерелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 5-79/тэ карарына кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2015 № 5-48/тэ карарына 1 нче кушымта

# «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2016-2018 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Җайга салынулы оешманың аталышы | тариф төре | Ел | Җылысаклагыч төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| 1.1 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (җылылык энергиясен ЕТО-2* системасына тапшыру (магистраль җылылык челтәрләренә тоташтырылган кулланучылар) | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 185,00 | - |
| | | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 189,17 | - |
| | | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 189,17 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 3470,58 | - |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 2070,00 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 2155,10 | - |
| 1.2 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (җылылык энергиясен ЕТО-2* системасына тапшыру (бүлүче җылылык челтәрләренә тоташтырылган кулланучылар) | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 799,99 | - |
| | | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 801,03 | - |
| | | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 660,00 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 674,31 | - |

| № п/п | Җайга салынулы оешманың аталышы | тариф төре | Ел | Җылысаклагыч төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 650,00 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 675,14 | -» |

* - Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 130 номерлы боерыгы белән расланган Казан ш. җылы белән тәэмин итү схемасына нигезләнеп билгеләнде.»

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге